РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Каенлинского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Каенлы авыл җирлеге
Советы

423560, Нижнекамский район,
с. Каенлы, ул. Ленина, 44

423560, Түбән Кама районы,
Каенлы авылы, Ленин урамы, 44

тел./факс (8555) 44-91-26, электронный адрес: Kaenlinskoe.sp @tatar.ru, сайт: www. kaenlinskoe-sp.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

2020 елның 25 мае № 6

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге Советының 2014 елның 19 февралендәге 4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет сәясәте турында Нигезләмәнең аерым нормаларының гамәлдә булуын туктатып тору һәм үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 9 статьясы, «Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2020 елда федераль бюджетны үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 1 апрелендәге 103-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 5 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Каенлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге Советының 2014 елның 19 февралендәге 4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет сәясәте турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 19 статьяның 15 абзацында «акчаларны исәпкә алу буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2 33 статьяның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Шәһәр бюджеты үтәлешенә казначылык хезмәт күрсәтү Федераль казначылык тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

1.3 34 статьяда

4 пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа абзац өстәргә:

«- Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә, субсидияләр бирү өчен агымдагы финанс елы башына файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләренең калдыкларыннан артмаган күләмдә, финанс тәэминаты чыганагы булып мондый субсидияләр торган, аларны бирү хисап финанс елында субсидияләр алучыларның акчалата йөкләмәләрен түләү очен кирәкле акчалар чикләрендә гамәлгә ашырылган, юридик затларга субсидияләр бирү өчен агымдагы финанс елының бюджет ассигнованиеләре арткан очракта;»;

11 абзацны 12 абзац дип санарга;

1.4 35 статьяның 1 пунктында «кассага кергән акчалар» сүзләрен «кергән акчалар» сүзләренә алмаштырырга, «касса түләүләре» сүзләрен «күчерүләр» сүзләренә алмаштырырга, «бюджетның бердәм счетының фараз халәтен билгеләү максатларында, вакытлы касса аермасын һәм вакытлыча буш акча күләмен дә кертеп» сүзләрен өстәргә;

1.5 36 статьяда

1 пунктның икенче абзацында «Федераль казначылык органнары счетларыннан» сүзләрен «кергән акчаларны исәпкә алу һәм бүлү буенча операцияләрне гамәлгә ашыру һәм күрсәтү өчен казначылык счетларыннан» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-артык бүленгән суммаларны күчерү, артык түләнгән яки артык алынган суммаларны кире кайтару, шулай ук мондый кире кайтаруны вакытында башкармаган өчен процентлар суммасы һәм артык алынган суммаларга исәпләнгән процентлар;»;

1 пунктның 4 абзацында «салымнар һәм җыемнар турында» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.6 37 статьяда

3 пунктның 1 абзацында «агымдагы финанс елында (агымдагы финанс елында һәм план чорында)» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 пунктта «түләү хезмәтләре һәм» сүзләрен «казначылык түләүләрен башкару турында боерыклар (алга таба - боерык) һәм» сүзләренә алмаштырырга, «түләү документлары белән» сүзләрен «боерыклар белән» сүзләренә алмаштырырга;

1.7 39 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«39 Шәхси счетлар

Бюджет керемнәре администраторларының операцияләрен исәпкә алу, РФ Бюджет кодексының 220.1 статьясы нигезендә, Федераль казначылыкта ачыла торган шәхси счетларда башкарыла.

Җирле бюджетны үтәү буенча операцияләрне исәпкә алу, РФ Бюджет кодексы белән билгеләнгән очраклардан тыш, бюджет һәм финанслар департаментына Федераль казначылыкта ачыла торган шәхси счетларда, бюджет һәм финанслар департаментында ачыла торган шәхси счетларда башкарыла.»;

1.8 35 статьяның 2 пунктындагы икенче абзацын, 42 статьяны, 44 статьяның 2,3 пунктларын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге Советының 2014 елның 19 февралендәге 4 номерлы карары белән расланган Каенлы авыл җирлегенең бюджет-финанс сәясәтен билгеләүче Нигезләмәнең 17 статьясындагы 2 пункты, 29 статьясындагы 10 пункты, 41 статьясындагы 1 пункты, 46 статьясындагы 3 пункты (бюджет үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмәләр әзерләү сроклары

өлешендә), 46 статьясындагы 6 пункты (сроклар өлешендә) гамәлдә булуын 2021 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

3. Әлеге карарның 1 пункты 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә игълан итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Каенлы авыл жирлеге
башлыгы

Ф.М. Набиуллин